Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының кырык алтынчы утырышы

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге советы утырышы
# КАРАРЫ

28 март 2019 ел № 126

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июлендәге 69 номерлы карары белән расланган бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүче коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июлендәге 69 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүче коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына туры китерү максатында, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүче коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәнең 1 пунктында, «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан итергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы П.Д.Гаврилов